КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 70

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636; 2017 ел, 15 май, 282 нче; 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 205 нче; 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче; 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче; 2020 ел, 2 март, 155 нче; 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

3.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.17. Грантларның күләмнәре түбәндәгечә тәшкил итә:

I урын өчен – иң күбе 1 млн.сум, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә иң күбе 28,5 мең сум, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә иң күбе 28,5 мең сум;

II урын өчен – иң күбе 800,0 мең сум, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә иң күбе 22,5 мең сум, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә иң күбе 22,5 мең сум;

III урын өчен – иң күбе 600,0 мең сум, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә иң күбе 17,5 мең сум, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә иң күбе 17,5 мең сум;

IV урын өчен– иң күбе 400,0 мең сум, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә иң күбе 14,0 мең сум, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә иң күбе 14,0 мең сум;

V урын өчен – иң күбе 200,0 мең сум, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен бүләкләүгә иң күбе 7,5 мең сум, территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләүгә иң күбе 7,5 мең сум.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.3[1] пункт өстәргә:

«4.3[1]. Грант акчасын тотарга рөхсәт ителә торган чаралар исемлеге:

территорияне төзекләндерү (көнкүреш калдыкларын чыгару, утильләштерү һәм эшкәртү, кардан чистарту (аны чыгару), яшелләндерү, ишегалды территорияләрен һәм урамнарын яктырту);

шәфкатьлелек һәм хәйрия акцияләрен оештыру, мондый акцияләрне үткәргәндә җирле үзидарә органнарына, хәйрия фондларына, башка оешмаларга, гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү (бина, автомобильләр, автобуслар арендалау, азык-төлек продуктлары, медицина эшләнмәләре, индивидуаль саклану чаралары, гигиена чаралары сатып алу, социаль ашханәләр оештыру, халыкның социаль якланмаган катламнары, ятим балалар, инвалидлар өчен беренчел кирәк-яраклар сатып алу, хәйрия фондларына максатчан кертемнәр);

халыкның ял итү сыйфатын яхшырту (мәдәни, спорт һәм ял итү чараларын оештыру һәм үткәрү);

торак хуҗалыгында җылылык, электр энергиясен, газ һәм суны югалтуны киметүгә юнәлдерелгән эшчәнлек;

ял итү урыннары территорияләрен, паркларны, скверларны төзекләндерү (коймалар, кече архитектура формалары, эскәмияләр, контейнерлар урнаштыру);

юл өслекләрен һәм тротуарларны ремонтлау;

балалар һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, шул исәптән спорт инвентарен сатып алу (кую);

бәйрәм чараларын үткәрү (декорацияләр, бүләкләр сатып алу);

территориаль иҗтимагый үзидарәнең эшчәнлеген оештыру (гражданнарны кабул итү өчен оештыру техникасы, җиһазлар сатып алу, мәгълүмат стендларын эшләү (сатып алу), канцтоварлар һәм хуҗалык инвентарьлары (көрәк, себерке, бензин белән эшли торган пычка, мотоблок, печән-үлән чабу машинасы) сатып алу;

видеокүзәтү системалары сатып алу һәм аларны урнаштыру;

территориаль иҗтимагый үзидарә активын бүләкләү.»;

4.7 пунктта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече» сүзләрен «бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4.8 пунктта «Министрлык тарафыннан расланган форма» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма» сүзләренә алмаштырырга;

4.9 пунктта:

өченче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка бюджетара трансферт акчасы исәбеннән чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап һәм башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап бирү сроклары һәм формалары;»;

4.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Вәкаләтле органнар тарафыннан түбәндәгеләр Министрлыкка кертелә:

башка бюджетара трансферт акчасы исәбеннән чыгымнар турында хисап. Әлеге хисап квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 7сеннән да соңга калмыйча тапшырыла;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап. Ул хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча тапшырыла;

бу Нигезләмәнең 8 нче кушымтасында бирелгән форма буенча башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап. Ул хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча тапшырыла;

килешүдә каралган срокларда һәм форма буенча өстәмә хисаплылык (килешүдә шулай билгеләнгән очракта).»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Нигезләмәнең 5 нче кушымтасындагы таблицаның 4 графасы исемендә «җитәкчене җирле үзидарә органнары каршындагы киңәшмә һәм башка органнар составына кертү» сүзләрен «халык белән эшләү» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 8 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан Н.В.Кондратованы чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын Юлай Рим улы Миңнуллинны кертергә;

Илнур Мәхмүт улы Гариповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә
8 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 гыйнвар, 70 нче
карары редакциясендә)

Форма

Грант акчасын файдалану турында
хисап

Моның белән «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм приз алучыларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансферт бирү турындагы 20____ елның ________ _______ номерлы килешү нигезендә бирелгән грант акчасын тотуны раслыйм.

| Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | Үткәрү срогын, урынын һәм катнашучыларын (башкаручыларын) күрсәтеп, чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исеме | Катнашучылар саны, кеше | Чаралар үткәрүне, эшләр башкаруны яки хезмәтләр күрсәтүне раслый торган документлар исеме һәм реквизитлары | Барлык акча, шул исәптән бюджеттан тыш акча, сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Хисапка бу хисапның мәгълүматларын раслый торган документларның тиешле рәвештә расланган күчермәләре һәм фотоматериаллары ____ биттә _____ нөсхәдә теркәлә.

_____________________ муниципаль районы (шәһәр округы)
башкарма комитеты – вәкаләтле орган җитәкчесе
Ф.И.Ат.ис.: ________________ ________ 20___ ел, «______» ___________
(соңгысы – булганда) ( имза)

_____________________ муниципаль районы (шәһәр округы)
Финанс-бюджет палатасы – вәкаләтле орган җитәкчесе
Ф.И.Ат.ис.: ________________ ________ 20___ ел, «______» ___________
(соңгысы – булганда) ( имза)

_____________________ муниципаль районы (шәһәр округы)
территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесе
Ф.И.Ат.ис.: ________________ ________ 20___ ел, «______» ___________
(соңгысы – булганда) ( имза)

_____________________________